РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» октября 2025 ел г. Альметьевск № 2465

Гражданнарны наем шартнамәләре
буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар
дип тану максатларында гражданнарның
һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә
әгъзаларының кеременең һәм аларның
салым салынырга тиешле мөлкәтләре
хакының максималь күләмен билгеләү турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 2 яртыеллыгына гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен түбәндәге очракларда билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен - 1 939 518 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 3 879 036 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 5 818 554 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 7 758 072 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 9 697 590 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 11 637 108 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 13 576 626 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 15 516 144 сум

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме тәшкил итә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче гражданга – 54 694 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 54 694 сум;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 54 694 сум.

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә

Зак. № 305-2000

әгъзаларының керемёнең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү турында» 2024 елның 25 апрелендәге 1601 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 01 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.М. Каюмов